Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел № 367

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым Указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында»гы 253 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга 1 нче кушымта 3 бүлектә «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе» 3.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.2.6 пунктча белән тулыландырырга:

«3.2.6. Әлеге нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3, 3.2.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлар «б» һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнәмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «д» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге нигезләмәнең 3.9, 3.10.3 һәм 3.11.1 пунктлары яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов